ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.03.2021 № 168

Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының яңа редакциясен раслау турындагы 2020 елның 13 ноябрендәге 944 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,

КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2020 елның 13 ноябрендәге 944 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6 пунктта (*хакимият органнары карамагында булган белешмәләр*):

«Йорт кенәгәсеннән өземтә» яисә «Йорт кенәгәсеннән өземтә (әгәр документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән булса)» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгы яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар»;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

«4) Граждан хәле актларын теркәү органнары-14 яше тулмаган гариза бирүченең гаилә әгъзалары өчен бала туу турында таныклык;

5) Гариза бирүче һәм/яки аның гаилә әгъзалары өчен никах теркәү турында таныклык-гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

6) Граждан хәле актларын теркәү органнары - ата булуны тану турында таныклык;

7) Аерылышу турында таныклык-гражданлык хәле актларын теркәү органнары;

8) Россия Пенсия фонды- опека һәм попечительлек турында мәгълүмат.».

3.4.1 пунктында (ведомствоара запрослар җибәрү):

«йорт кенәгәсеннән өземтәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү белешмәләре» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

«4) бала туу турында таныклык;

5) язылышу турында таныклык;

6) ата булуын раслау турында таныклык;

7) аерылышу турында таныклык;

8) опека билгеләү турында мәгълүмат».